**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 30 март № 200

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында инвалидлар өчен объектларның һәм хезмәтләрнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре мәгънәләрен күтәрүгә юнәлдерелгән чаралар планын («юл картасын») раслау турында» 2015 ел, 28 сентябрь, 716 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында инвалидлар өчен объектларның һәм хезмәтләрнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре мәгънәләрен күтәрүгә юнәлдерелгән чаралар планын («юл картасын») раслау турында» 2015 ел, 28 сентябрь, 716 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендәге «2015 – 2020 елларга» сүзләрен «2015 – 2030 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

1 нче пунктта «2015 – 2020 елларга» сүзләрен «2015 – 2030 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

3 нче пунктка «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына» сүзләреннән соң «, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына, Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетына» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган 2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында инвалидлар өчен объектларның һәм хезмәтләрнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре мәгънәләрен күтәрүгә юнәлдерелгән чаралар планын («юл картасын») яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\200.doc